Республика Татарстан
Новоимянское сельское
поселение Яңа Имәновского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Яңа Имән муниципаль
районының Яңа Имән
авыл җирлеге

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.12.2021**

**КАРАР**
**№15**

Татарстан Республикасы Яңа Имән муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 21 сентябрендагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 21 сентябрндагы 12 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 -10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адреслы системасын эксплуатацияләүгә бәйле Регламентта кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 декабрендәге 1221 номерлы карары белән төгәл кулланыла.

1.2. 1.5 пунктының 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында. «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү яки Башкарма комитет нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4 пунктында. «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http:/ www.sarmanovo.tatar.ru веб адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Яңа Имән җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р. Ф.Гараев